ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.04.2017 Казан ш. № 7-2/т

Даими ташулар буенча муниципаль маршрутларда Татарстан Республикасының «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә җәмәгатьчелек транспорты белән пассажирларны һәм багажны даими ташуларга чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәрнең җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы, «Автомобиль транспорты һәм шәһәрнең җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәрнең җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны тормышка ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, даими ташулар буенча муниципаль маршрутларда Татарстан Республикасының «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә җәмәгатьчелек транспорты белән пассажирларны һәм багажны даими ташуларга чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Чаллы ш. шәһәр юнәлешендә җәмәгатьчелек транспортында пассажирлар һәм багаж ташуларга чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге 7-6/т номерлы карарының 1 пунктының көчен югалтуын таныырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
21.04.2017 ел № 7-2/т карарына
кушымта

# Даими ташулар буенча муниципаль маршрутларда Татарстан Республикасының «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә җәмәгатьчелек транспорты белән пассажирларны һәм багажны даими ташуларга чик дәрәҗә максималь тарифлар

| Транспорт төре | Бер мәртәбә бару һәм бер багажны алып бару урыны өчен чик дәрәҗәдә максималь тариф (сум) | | |
|---|---|---|---|
| | билетны транспорт чарасы салонында сатып алганда | юл өчен озак файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә | |
| | | 1 мәртәбә баруга[1] | 50 һәм аннан күбрәк мәртәбә баруга [2] |
| Автобус | 22 | 20 | 15 |
| Трамвай | 22 | 20 | 15 |

<1> шәһәр юнәлешендә барганда, төгәл сумма чикләрендә бару хокукын бирә торган, озак файдаланылучы билет ярдәмендә түләгәндә;

<2> шәһәр юнәлешендә күрсәтелгән чор дәвамында төгәл билгеле күләмдә йөрү хокукын бирә торган, озак файдаланылучы билет ярдәмендә түләгәндә.

Искәрмә. Багажны алып бару бәясен түләү юл бәясен түләүдән аерым гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге